**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МИХАЙЛОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ XI УТЫРЫШЫ**

**К А Р А Р № 21**

Михайловка ав. 25 май 2021 ел

**Мөслим муниципаль районы Михайловка авыл җирлеге Советының 2016 елның 22 мартындәге 15 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Михайловка авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Михайловка авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

«Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның 12.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 26 июлендәге 251-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясына һәм «Контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасына яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасына гражданнарның, муниципаль вазыйфаларны яисә җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибе хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 24 апрелендәге 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы», Мөслим муниципаль районы Михайловка авыл җирлеге Советы Уставы нигезендә, Мөслим муниципаль районы Михайловка авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. Мөслим муниципаль районы Михайловка авыл җирлеге Советының 2016 елның 22 мартындәге 15 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Михайловка авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында, шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Михайловка авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле 21 пункт белән тулыландырырга:

«21. Мөслим муниципаль районы Михайловка авыл җирлеге Советы депутаты муниципаль вазыйфасын биләүче һәм үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә башкаручы зат депутат булып сайланган, аңа вакантлы депутат мандатын тапшырган яисә даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны туктаткан көннән соң дүрт ай эчендә керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында, шулай ук, хисап чоры дәвамында «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы

Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган алыш-бирешләр башкарылган очракта, белешмәләр тапшыру елыннан алдагы һәр ел (хисап чоры) өчен белешмәләр тапшыра. Хисап чорында мондый алыш-бирешләр башкарылмаган очракта, күрсәтелгән зат бу хакта Татарстан Республикасы Президентына, керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү өчен, махсуслаштырылган мәгълүмат ресурсы (dohod.tatar.ru) ярдәмендә әлеге Нигезләмәгә кушымта формасы буенча хәбәрнамә юллау юлы белән хәбәр итә.

2) түбәндәге эчтәлекле 3 номерлы кушымта белән тулыландырырга:

Мөслим муниципаль районы Михайловка авыл җирлеге Советының 2016 елның 22 мартындәге 15 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Михайловка авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Михайловка авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакындагы нигезләмәгә
3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Президенты**

____________________________________

**Хәбәрнамә**

Мин, ____________________________________________________________,
*фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта)*
______________________________________________________ муниципаль районы
*муниципаль район исеме*
___________________________________________________ авыл җирлеге депутаты,
*авыл җирлегенең вәкиллекле органы исеме*
«___»______________ ________елда туган, паспорт сериясе _______№____________
__________________________________________________________________________,
*паспортны бирү датасы һәм биргән орган*

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 121 статьясындагы 4.2 өлеше һәм «Муниципаль вазыйфа яки контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 4.1 өлеше нигезендә Сезгә «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган (безнең (минем һәм минем ирем (хатыным) керемебезнең гомуми суммасы хисап чорына кадәрге

соңгы өч елдагы гомуми керемнән артып китә торган җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча килешүләр) минем (хатыным) һәм (яисә) балигъ булмаган балалар тарафыннан хисап чоры дәвамында 20___ елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр алыш-биреш булмады, дип хәбәр итәм.

Әлеге мәгълүматларның дөреслеген раслыйм.

«___»___________ 20____ел.

_____________________________________________

*хәбәрнамә тапшырган затның имзасы*

_____________________________________________________________________________

*(хәбәрнамәне кабул итүгә вәкаләтле затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта), имзасы».*

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Михайловка авыл җирлеге башлыгы** **Р.Х. Исламов**